КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 август г.Казань № 991

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Горький урамы, 17 нче йорт адресы буенча бина фасадына мемориаль такта кую турында

Бөек рус язучысы Максим Горький истәлеген мәңгеләштерү максатларында, шулай ук аның 155 еллыгы уңаеннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенең, «Татарстан Республикасы Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Красновидово авылы, Горький урамы, 17 нче йорт адресы буенча Красновидово авылында урнашкан «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – А.М.Горький музее бинасы фасадына Максим Горький истәлегенә багышланган татар һәм рус телләрендә түбәндәге текст белән мемориаль такта кую турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

«На этом месте находились дом и
торговая лавка М.А.Ромася, где
летом 1888 г. жил и работал великий
русский писатель Максим Горький

___________

Бу урында 1888 елның җәендә
бөек рус язучысы Максим Горький
яшәгән һәм эшләгән М.А.Ромась йорты
һәм сәүдә кибете урнашкан булган».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин